Министерство образования и науки Республики Татарстан
ГАПОУ «Нижнекамский многопрофильный колледж»

СОГЛАСОВАНО
Зам. директора по НМР
__________ В.П. Кузиева
"21" ____03____ 2023 г.

УТВЕРЖДАЮ
Зам. директора по ТО
__________ Л.М. Владимирова
«21» ____03____ 2023 г.

**Комплект контрольно-оценочных средств**
ОУД.03 Татар теле
ОУД.03 Татарский язык
(базовый уровень)
(Татар телле укучылары өчен)

**Профессия:** 15.01.05 Сварщик (ручной и частично механизированной сварки (наплавки)
**Квалификация:** Сварщик ручной дуговой сварки плавящимся покрытым электродом – Сварщик ручной дуговой сварки неплавящимся электродом в защитном газе
**Форма обучения** – очная
**Нормативный срок обучения** – 1 год 10 мес. на базе основного общего образования
**Профиль получаемого профессионального образования** – технологический

Нижнекамск
2023

1. Урта гомуми белем бирү федераль дәүләт стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы 17.05.2012 N 413 приказынанан “Урта гомуми белем бирү ФДБС раслау турында") һәм Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 12.08.2022 г., №732 "Урта гомуми белем өчен федераль дәүләт белем бирү стандартларын раслау турында” гы приказына;

2. ДАҺБУ “Түбән Кама шәһәренең күппрофильле көллияте” уку планына;

3. ФДБУО ӨҺБ “Һөнәри белемне үстерү институты” тарафыннан эшләнгән программаларга нигезләнеп Урта һөнәри белем бирү уку йортлары өчен Федераль дәүләт белем бирү стандарты буенча (алга таба – ФДБС) 15.01.05 Эретеп ябыштыручы ( кулдан һәм өлешчә механизалаштырылган эретеп ябыштыру (наплавка)) һөнәре буенча төзелгән.

ОУД.03 Татар теле фәне буенча тикшерү-бәяләү материаллары комлекты эш программасына нигезлщнеп төзелде.

4. Профиле буенча –технологик.

Төзүче оешма: ДАҺБУ “Түбән Кама шәһәренең күппрофильле көллияте”

Төзүче: 1. Проскурина Ромина Ильмар кызы;
2. Хәйретдинова Зөлфия Рафик кызы.

ДАҺБУ “Түбән Кама шәһәренең күппрофильле көллияте” предметара цикл коммисиясендә каралды һәм тәкъдим ителде:
Гомуми белем бирү укытучыларының, гомуми гуманитар һәм социаль игътисад укыту циклында.

Җыелыш беркәтмәсе № 8 « 13 » март 2023 ел.

Гомуми белем бирү укытучыларының, гомуми гуманитар һәм социаль игътисад укыту циклы рәисе

Сибгатуллина А.Д.

## Эчтәлек


| | | Бит. |
|---|---|---|
| **1** | **Тикшерү-бәяләү материаллары комлекты паспорты** | |
| 1.1. | Гомуми нигезләмә | 4 |
| 1.2. | Тикшерү-бәяләү методлары һәм формалары, укыту фәненең үзләштерү нәтиҗәсе | 4 |
| **2.** | **Тикшерү-бәяләү материаллары** | |
| 2.1 | Телдән җавап бирү өчен сораулар | 10 |
| 2.2. | Гамәли эшләр исемлеге | 15 |
| 2.3 | Бүлек һәм темалар буенча тикшерү эшләре | 17 |
| **3.** | **Арадаш аттестациянең тикшерү-бәяләү материаллары** | |
| 3.1 | Диф.зачет өчен тикшерү-бәяләү материаллары | 19 |
| 3.2. | Җаваплар эталоны | 26 |
| 3.3 | Зачет ведомосте | 29 |

# 1. ТИКШЕРҮ-БӘЯЛӘҮ МАТЕРИАЛЛАРЫ КОМПЛЕКТЫНЫҢ ПАСПОРТЫ

## 1.1.Гомуми нигезләмә

15.01.05 эретеп ябыштыручы ( кулдан һәм өлешчә механизалаштырылган эретеп ябыштыру (наплавка)) һөнәре буенча гомуми укыту ОУД.03 “Татар теле” фәненең программасына нигезләнеп эшләнгән, студентларның белем дәрәҗәсен бәяләүче тикшерү-бәяләү материаллары комлекты.

*Тикшерү-бәяләү материаллары комлекты үз эченә ала:*

- чираттагы тикшерү эше;
- диф.зачет эше.

## 1.2.Тикшерү-бәяләү методлары һәм формалары, укыту фәненең үзләштерү нәтиҗәсе

Укыту фәненең үзләштерү нәтиҗәсе булып шәхси, метапредмет һәм предмет (күнекмәләр, белемнәр) нәтиҗәләре булып тора. Язмача һәм телдән сорау шулай ук укучыларның гамәли, үзлектән, тест, тикшерү эшләре, индивдуаль бирем һ. б. укучыларның башкару процессын тикшерү-бәяләү нәтиҗәсендә укуытучы ярдәмендә гамәлгә ашырыла.

| **Гомуми компетенцияләр (ГК) (Общие компетенции) (ОК), Шәхси тәрбия нәтиҗәләре (ШН) (Личностные результаты воспитания) (ЛР)** | **Фәнне үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре (Планируемые результаты освоения дисциплины)** | | **Бәяләү чаралары төре һәм укыту нәтиҗәләрен бәяләү** |
|---|---|---|---|
| | **Шәхси нәтиҗәләр (ШЛ) Личностные предметные (ЛП), Метапредмет нәтиҗәләре (МН) метапредметные ( МП) результаты** | **Предмет нәтиҗәләре (ПН), Предметные результаты (П)** | |
| **ГК 04.** Коллективта һәм төркемдә эффектив аралашу һәм эшләү. (**ОК 04.** Эффективно взаимодействовать и работать в коллективе и команде);<br><br>**ШН.4** Хезмәт кешеләренә хөрмәт күрсәтүче, үз эшенең кыйммәтен | -үз-үзеңне үстерүгә, мөстәкыйльлеккә һәм үзбилгеләнүгә әзерлек (готовность к саморазвитию, самостоятельности и самоопределению);<br>- фәнни-эзләнү эшчәнлек күнекмәләрен, проект һәм социаль эшчәнлек күнекмәләрен үзләштерү (овладение навыками учебно-исследовательской, проектной и социальной деятельности); | - формаль һәм формаль булмаган шәхесара һәм мәдәниара аралашу ситуацияләрендә тыңлау, уку, сөйләү һәм язу күнекмәләренең үзара бәйләнешен, Туган телдә төрле формаларда һәм төрле темаларга иркен аралаша алу күнекмәләрен камилләштерү; (совершенствовать умения аудирования, чтения, говорения и письма, обеспечивающих эффективное взаимодействие в ситуациях формального и неформального межличностного и межкультурного общения, умения свободно общаться на родном языке в | Телдән эшләү.<br>Кызыклы бирем.<br>Эш кәгазьләре белән эш.<br>Тестлар белән эш.<br>Укучылар үз белемнәрен һәм осталыкларын бәяләү.<br>Диагностик эш.<br>Тикшерү эше.<br>Презентацияләр.<br>Тест биремнәрен үтәү; гамәли эшләр һәм ситуация |

| | | | |
|---|---|---|---|
| аңлаучы. Шәхси һәм һөнәри конструктив «циффрлы эз» челтәр мохитендә формалашырга омтыла (**ЛР.4** Проявляющий и демонстрирующий уважение к людям труда, осознающий ценность собственного труда. Стремящийся к формированию в сетевой среде личностно и профессионального конструктивного «цифрового следа»);<br>**ШН. 8** Төрле этномәдәни, социаль, конфессиональ һәм башка төркемнәр вәкилләренә хөрмәт һәм ихтирам күрсәтү. Күпмилләтле Россия дәүләтенең мәдәни традицияләрен һәм кыйммәтләрен саклау, арттыру һәм трансляцияләү (**ЛР.8** Проявляющий и демонстрирующий уважение к представителям | **Универсаль коммуникатив гамәлләрне үзләштерү:**<br>**б) уртак эшчәнлек: (Овладение универсальными коммуникативными действиями: б) совместная деятельность:)**<br>- төркем һәм шәхси эшчәнлекнең өстенлекләрен дөрес аңлау һәм куллану (понимать и использовать преимущества командной и индивидуальной работы);<br>- уртак эшчәнлекнең максатларын кабул итү, аңа ирешү буенча гамәлләрне оештыру һәм координацияләү: эш планын төзү, катнашучыларның фикерләрен исәпкә алып рольләрне бүлү һәм уртак эш нәтиҗәләре турында фикер алышу (принимать цели совместной деятельности, организовывать и координировать действия по ее достижению: составлять план действий, распределять роли с учетом мнений участников обсуждать результаты совместной работы);<br>- реаль, виртуаль һәм комбинацияле үзара бәйләнеш шартларында эшне координацияләү һәм башкару (координировать и выполнять работу в условиях реального, виртуального и комбинированного | различных формах и на разные темы; использовать языковые средства в соответствии с ситуацией и сферой общения) ;<br>- ситуациягә һәм аралашу өлкәсенә игътибар итеп, тел чараларын куллану; (развивать культуру владения родным языком с учётом его функциональных возможностей; свободное использование активного словарного запаса, овладение основными стилистическими ресурсами лексики и фразеологии родного языка);<br>- туган телне белү культурасын, аның функциональ мөмкинлекләрен исәпкә алып үстерү сүзлек запасын иркле куллану, Туган тел ликасының һәм фразеологиясенең төп стилистик ресурсларын үзләштерү;<br>(развивать культуру владения родным языком с учётом его функциональных возможностей; свободное использование активного словарного запаса, овладение основными стилистическими ресурсами лексики и фразеологии родного языка);<br>- аралашуның төрле өлкәләрендә, шул исәптән интернет-коммуникациядә Туган телдә сөйләм этикеты кагыйдәләрен дөрес һәм куллану күнекмәләрен камилләштерү. (совершенствовать умения использовать правила речевого этикета на родном языке в различных сферах общения, включая интернет-коммуникацию). | нәтиҗәләре.<br>Эшлекле уен рәвешендә биремнәрне үтәү (диалоглар, меню өчен ризыкларның тасвирламаларын төзү, ризыкларга презентацияләр, монологик сүз һ. б.) гамәли эшләр.<br>Белем бирү, тәрбия чараларында катнашу.<br>Фән һәм һөнәри юнәлештәге, иҗади конкурсларда катнашу.<br>Эшлекле уен рәвешендә биремнәрне үтәү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| различных этнокультурных, социальных, конфессиональных и иных групп. Сопричастный к сохранению, преумножению и трансляции культурных традиций и ценностей многонационального российского государства). | взаимодействия);<br>- позитив стратегик тәртипне тормышка ашырутөрле ситуацияләрдә иҗат күрсәтү, инициативалы булу (осуществлять позитивное стратегическое поведение в различных ситуациях, проявлять творчество и воображение, быть инициативным ).<br>**Универсаль регулятив гамәлләрне үзләштерү:**<br>**г) үзеңне һәм башкаларны кабул итү: (Овладение универсальными регулятивными действиями:**<br>**г) принятие себя и других людей:)**<br>- эшчәнлек нәтиҗәләрен анализлаганда башка кешеләрнең фикерләрен һәм дәлилләрен кабул итү (принимать мотивы и аргументы других людей при анализе результатов деятельности);<br>- үз хокукыңны һәм башка кешеләрнең хаталарга хокукын тану ( признавать свое право и право других людей на ошибки);<br>- дөньяны бөтән кешеләр карашыннан аңлый белү сәлатен үстерү (развивать способность понимать мир с позиции другого человека). | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **ГК 05.** Социаль һәм мәдәни контекст үзенчәлекләрен исәпкә алып, РФ нең дәүләт телендә телдән һәм язмача коммуникацияне үтәү. (ОК 05. Осуществлять устную и письменную коммуникацию на государственном языке Российской Федерации с учетом особенностей социального и культурного контекста).<br>**ШН. 5** Мәдәнияткә, туган илгә, туган халкыбызга, Ватанга мәхәббәт нигезендә тарихи хәтергә тугрылыгын, күпмилләтле халык йолаларының кыйммәтләрен кабул итүне күрсәтү (**ЛР.5** Демонстрирующий приверженность к родной культуре, исторической памяти на основе любви к Родине, родному народу, малой родине, принятию традиционных ценностей многонационального народа России).<br>**ШН. 8** Төрле этномәдәни, социаль, конфессиональ һәм башка төркемнәр вәкилләренә хөрмәт һәм ихтирам күрсәтү. | **Эстетик тәрбия өлкәсендә: (в области эстетического воспитания:)**<br>-дөньяга, шул исәптән көнкүреш, фәнни һәм техник иҗат, спорт, хезмәт эстетикасы һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләргә эстетик мөнәсәбәт сәләтен үстерү (эстетическое отношение к миру, включая эстетику быта, научного и технического творчества, спорта, труда и общественных отношений);<br>- үзенең һәм башка халыкларның төрле сәнгать төрләрен, гореф-гадәтләрен һәм иҗатын кабул итү, сәнгатьнең эмоциональ тәэсирен тою сәләтен үстерү (способность воспринимать различные виды искусства, традиции и творчество своего и других народов, ощущать эмоциональное воздействие искусства);<br>- шәхес һәм җәмгыять өчен Ватан һәм дөнья сәнгате, этник гореф-гадәтләр һәм халык иҗаты әһәмиятле булуына ышану сәләтен үстерү (убежденность в значимости для личности и общества отечественного и мирового искусства, этнических культурных традиций и народного творчества);<br>- төрле сәнгать төрләрендә үз-үзеңне күрсәтүгә әзерлек, иҗади шәхес сыйфатларын күрсәтергә омтылу сәләтен үстерү (готовность к самовыражению в разных видах искусства, стремление проявлять качества творческой личности);<br>**Универсаль аралашу чараларын** | - туган телнең кеше, җәмгыять һәм дәүләт тормышында әһәмиятен аңлауның, туган телгә карата кадерле/хөрмәтле мөнәсәбәтнең , Туган тел һәм туган мәдәниятнең үзара бәйләнеше турында күзаллауларның формалашуы, туган телдә Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләренең чагылышы турында күзаллау ( сформированность представления о роли и значении родного языка в жизни человека, общества, государства; сформированность ценностного отношения к родному языку; представлений о взаимосвязи родного языка и родной культуры, об отражении в родном языке российских традиционных духовно-нравственных ценностей);<br>- эффективлы үзара эшне тәэмин итү, туган телдә төрле темада, формада, өлкәдә иркен аралашып, тел чараларын кулланып, формаль һәм формаль булмаган ситуацияләрдә шәхесара һәм мәдәниара аралашу күнекмәләрен камилләштерү (совершенствовать умения аудирования, чтения, говорения и письма, обеспечивающих эффективное взаимодействие в ситуациях формального и неформального межличностного и межкультурного общения, умений свободно общаться на родном языке в различных формах и на разные темы);<br>- укыган һәм тыңланган, шул исәптән төрле форматтагы (гипертекст, графика, инфографика һ. б.), текстларны эшкәртү, икенчел һәм үз текстларын төзү, редакцияләү күнекмәләрен формалаштыру (формировать умения переработки прочитанных и прослушанных текстов, включая тексты разных форматов (гипертексты, графика, инфографика и др.), создание вторичных текстов, редактирования собственных текстов);<br>- туган тел һәм сөйләм функциональ-мәгънә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Күпмилләтле Россия дәүләтенең мәдәни традицияләрен һәм кыйммәтләрен саклау, арттыру һәм трансляцияләү (**ЛР.8** Проявляющий и демонстрирующий уважение к представителям различных этнокультурных, социальных, конфессиональных и иных групп. Сопричастный к сохранению, преумножению и трансляции культурных традиций и ценностей многонационального российского государства). | **үзләштерү: а) аралашу: (Овладение универсальными коммуникативными действиями: а) общение:)**<br>- тормышның барлык өлкәләрендә аралашуны гамәлгә ашыру (осуществлять коммуникации во всех сферах жизни) ;<br>- сөйләмсез аралашу чараларын тану, социаль билгеләрнең мәгънәсен аңлау, конфликтлы ситуацияләрнең алшартларын тану һәм конфликтларны йомшарту (распознавать невербальные средства общения, понимать значение социальных знаков, распознавать предпосылки конфликтных ситуаций и смягчать конфликты);<br>- тел чараларын кулланып үз карашыңны киң һәм логик итеп белдерү ( развернуто и логично излагать свою точку зрения с использованием языковых средств ). | төрләре турында белемнәрне системалаштыру; функциональ-стильле һәм жанрлы текстларны анализлау күнекмәләрен камилләштерү (систематизировать знания о функциональных разновидностях родного языка и функционально-смысловых типах речи; совершенствовать навыки анализа текстов разной функционально-стилевой и жанровой принадлежности на родном языке) ;<br>-туган телнең сурәтләү-белдерү мөмкинлекләре турында белемнәрне системалаштыру (систематизировать знания об изобразительно-выразительных возможностях родного языка);<br>- туган тел турында белемнәрне үсештә булган күренеш буларак системалаштыру аның дәрәҗәләрен һәм берәмлекләрен, эшчәнлек закончалыкларын шулай ук, туган телнең яшәү формаларын күзаллауга ия булу (систематизировать знания о родном языке как системе и развивающемся явлении, его уровнях и единицах, закономерностях его функционирования, иметь представление о формах существования родного языка*);<br>- туган телне үзләштерү мәдәниятен аның функциональ мөмкинлекләрен исәпкә алып үстерү; актив сүзлек запасын иректе куллану, туган телнең стиликасы һәм фразеологиясенең төп стилистик ресурсларын үзләштерү (развивать культуру владения родным языком с учётом его функциональных возможностей; свободное использование активного словарного запаса, овладение основными стилистическими ресурсами лексики и фразеологии родного языка);<br>- туган телнең тел нормалары турында белемнәрен системалаштыру; алар турында белемнәрне сөйләм практикасында куллану; тел чараларын дөрес куллану | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | һәм тел нормаларына туры килү күзлегеннән үзеңнең һәм башкаларның сөйләмен бәяләү (систематизировать знания о языковых нормах родного языка; применять знания о них в речевой практике; оценивать собственную и чужую речь с точки зрения правильности использования языковых средств и соответствия языковым нормам);<br>- туган телдә сөйләм этикеты кагыйдәләрен аралашуның төрле өлкәләрендә, шулай ук интернет-коммуникацияне кертеп сөйләм күнекмәләрен камилләштерү; (совершенствовать умения использовать правила речевого этикета на родном языке в различных сферах общения, включая интернет-коммуникацию);<br>- текст /текст фрагментларын туган телдән рус теленә һәм киресенчә тәрҗемә итү күнекмәләрен үстерү; сүзлекләр һәм белешмәлекләр, шул исәптән электрон формада мәгълүмати-белешмә системаларын куллану күнекмәләрен үстерү (развивать умения переводить текст /фрагменты текста с родного языка на русский и наоборот; развивать умения применять словари и справочники, в том числе информационно-справочные системы в электронной форме). | |

## 2. Тикшерү-бәяләү материаллары
## 2.1 Телдән тикшерү сораулары:

| Бүлекләр һәм темалар исемлеге | Сораулар |
|---|---|
| **Кереш.** | 1.Татар теле нинди телләр гаиләсенә керә?<br>2.Якынча татар телендә күпме кеше сөйләшә?<br>3.Нәрсә ул аккумулятив функция? |
| **1 нче бүлек АРАЛАШУ** | |
| Тема 1.1.<br>Аралашу. | 1.Аралашу функциясен икенче төрле ничек дип атыйлар?<br>2.Аралашуның коралы булып нәрсә санала?<br>3.Кешеләр бер-берсе белән ничек аралашалар? |
| Тема 1.2.<br>Аралашу төрләре. | 1.Аралашуның нинди төрләре була?<br>2.Якын кешеләр ничек аралаша?<br>4.Рәсми аралашу дип нинди аралашуны атыйлар?<br>5.Аралашу вакытында кемнәр өстен?<br>6.Гаиләдә аралашу кайсы төргә керә? |
| Тема 1.3.<br>Әдәплелек сыйфатлары. Итәгатле аралашу. | 1. Нәрсә ул сөйләм этикеты?<br>2. Ниди сүзләр белән сәламлиләр?<br>3. Синең якын кешеләрең бармы?<br>4. Якын кешеләрегә ничек эндәшергә?<br>5. Кеше белән хушлашканда нинди сүзләр әйтергә була?<br>6. Якыннарыңны бәйрәм белән ничек котлар идең?<br>7. Кешеләргә рәхмәт белдерәсең килсә ни дияр идең?<br>8. Гафу итенгәндә нишләр идең? |
| **2 нче бүлек ҺӨНӘР САЙЛАУ** | |
| Тема 2.1.<br>Һөнәр сайлау. | 1.Нинди һөнәрләрне беләсез?<br>2.Сезгә кайсылары охшый?<br>3.Ни өчен бу һөнәр сиңа охшый? |
| **3 нче бүлек ФОНЕТИКА.** | |
| Тема 3.1.<br>Сузык авазлар | 1. Авазлар нинди ике төргә бүленә?<br>2. Татар телендә сузыклар авазлар нинди ике төргә бүленә?<br>3.Ә рус теленнән кергән сүзләрлә ничек әйтелә? |
| Тема 3.2.<br>Тартык авазлар | 1.Ничә тартык аваз?<br>2.Тавыш һәм шау катнашы ягыннан тартык авазлар нинди төркемнәргә бүленәләр?<br>3.Нинди төр тартык авазларны шаулы авазлар диләр?<br>4. Кайсы төр тартык авазлар ясалганда тавыш та, шау да катнаша?<br>5.[м], [н], [ң] авазларын нинди авазлар диләр? |
| **4 нче бүлек. ЛЕКСИКА** | |
| Тема 4.1.<br>Синонимнар. | 1.Синоним нәрсә ул? Мисаллар китерегез.<br>2.Синонимнар ни өчен кирәк?<br>3.Синоним сүзләр бер-берсеннән ничек аерыла? |
| Тема 4.2.<br>Антонимнар | 1.Антонимнар дип нинди сүзләргә әйтәләр? Мисаллар китерегез.<br>2.Антонимнар ни өчен кирәк?<br>3.Антонимнарның синонимнардан аермасы нәрсәдә? |
| Тема 4.3.<br>Омонимнар. | 1.Омонимнар нинди сүзләр алар?<br>2. Оонимнар һәм паронимнар ничек аерылалар? Мисаллар китерегез.<br>3.Күп мәгънәле сүзләр белән омонимнар арасында нинди аерма бар? Мисаллар белән аңлатыгыз. |
| Тема 4.4.<br>Фразеология | 1.Нәрсә ул фразеологизм?<br>2.Фразеологизмнарны белү ни өчен кирәк?<br>3. Фразеологизмнардагы сүзләрне башка сүз белән алыштырырга |

| | |
|---|---|
| | ярыймы?<br>4.Фразеологизмнардагы сүзләр арасына башка сүзләр өстәп буламы? |
| **5 нче бүлек СӨЙЛӘМГӘ МӨНӘСӘБӘТЛЕ СТИЛЬ СИТУАЦИЯСЕ** | |
| Тема 5.1.<br>Стиль. Фәнни стиль. | 1.Нәрсә ул стиль?<br>2.Функциональ стиль дип әйтәләр?<br>3.Стильләрнең төрләрен санарга.<br>4. Фәнни стиль дип нинди стильне атыйлар?<br>5. Башка стильләрдән нәрсә белән аерылып тора?<br>6.Нинди төрләре бар? |
| Тема 5.2.<br>Публицистик стиль. | 1. Публицистик стиль дип нинди стильне атыйлар?<br>2. Башка стильләрдән нәрсә белән аерылып тора?<br>3.Нинди жанрлары бар?<br>4. Публицистикада нинди җөмләләр аз була?<br>5.Нинди рухта төзелә? |
| Тема 5.3.<br>Матур әдәбият стиле. | 1. Матур әдәбиятстиле дип нинди стильне атыйлар?<br>2. Сүрәт ясауда нинди чаралар катнаша?<br>3.Нинди сөйләм була?<br>4. Нинди жанрлары бар? |
| **6 нчы бүлек ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕ** | |
| Тема 6.1.<br>Белешмә. Раслама | 1.Белешмә нинди документ?<br>2.Раслама дип нинди документны атыйлар?<br>3.Белешмәдә нәрсәләр булырга тиеш түгел?<br>4.Белешмә бер генә эчтәлектә була аламы?<br>5.Расламада язылган әйбернең күләмен ничек язалар? |
| Тема 6.2.<br>Әмер. Гариза. | 1.Әмер нинди документ?<br>2. Гариза нинди документ?<br>3. Әмер ничек языла?<br>4. Гариза ничек языла? |
| Тема 6.3.<br>Боерык. Рәсми хат.<br>Хат. | 1.Нинди эчтәлекле хатлар була?<br>2. Хатны кемнәргә язалар?<br>3.Рәсми хат нәрсә ул?<br>4. Боерык ул нәрсә? |
| Тема 6.4.<br>Тәрҗемәи хәл.<br>Тасвирнамә. | 1.Тәрҗемәи хәл нинди документ?<br>2. Тәрҗемәи хәл ничек языла?<br>3. Тасвирнамә нәрсә ул?<br>4. Тасвирнамә ничек языла? |
| Тема 6.5.<br>Беркетмә. | 1.Беркәтмә нинди документ ул?<br>2. Беркәтмәне кем яза?<br>3. Беркәтмәне ничек дөрес итеп язалар? |
| **7 нче бүлек МОРФОЛОГИЯ** | |
| Тема 7.1.<br>Исем | 1.Исем дип нинди сүз төркеменә әйтәләр?<br>2.Исемне белдерүче нинди сүзләр беләсез?<br>3. Ялгызлыкка нинди исемнәр керә?<br>4.Ялгызлык исемнәр белән уртаклык исемнәрне бер-берсеннән ничек аерырга?<br>5.Нинди сан белән төрләнә?<br>6.Татар телендә ничә килеш бар? |
| Тема 7.2.<br>Сыйфат | 1.Сыйфатлар безгә ни өчен кирәк соң?<br>2.Сыйфатлар җөмләдә нинди сүз төркеменә бәйләнеп килә?<br>3.Сыйфатның ничә дәрәҗәсе бар? |

| | |
|---|---|
| | 4.Нинди дәрәҗәләр?<br>5. Мәгънәләренә карап , сыйфатлар нинди булалар? |
| Тема 7.3.<br>Сан | 1.Сан нинди сүз төркеме?<br>2.Ул нинди сорауларга җавап бирә?<br>3.Гарәп һәм рим цифрларының язылышындагы аермаларны әйтегез.<br>4.Сан ясалышы буенча ничә төркемгә бүленә?<br>5.Саннар кайсы җөмлә кисәге булып килергә мөмкин? |
| Тема 7.4.<br>Алмашлык | 1.Нинди сүзләргә алмашлыклар дип әйтәбез?<br>2.Алмашлыкның ничә төркемчәсе бар?<br>3.Ясалышлары буенча нинди төрләргә бүленәләр?<br>4. Алмашлыклар җөмләнең кайсы кисәкләре булалар?<br>5. .Зат алмашлыклары нәрсә белән төрләнә?<br>6.Сорау алмашлыклары нинди максатта кулланыла? |
| Тема 7.5.<br>Фигыль | 1. Фигыль нәрсәне белдерә?<br>2. Фигыльләргә нинди сораулар куела?<br>3.Фигыльләр ничек төрләнә?<br>4.Фигыль нинди заманнарда килә?<br>5.Эш яки хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә карап, фигыльнең нинди формалары була? |
| Тема 7.6.<br>Рәвеш | 1.  Рәвеш нәрсәне ачыклый? Кайсы яклап?<br>2.  Рәвеш нинди сорауларга җавап бирә?<br>3.  Рәвешнең нинди төркемчәләре бар? |
| Тема 7.7.<br>Теркәгечләр | 1. *һәм* теркәгече нинди кисәкләрне бәйләп килә?<br>2. Нинди мәгънә бәйләнешен белдерә ул?<br>3. *ләкин* теркәгече нинди кисәкләрне бәйли?<br>4.Нинди мәгънәне белдерә ул?<br>5. *яки* теркәгече нинди кисәкләрне бәйләп килә?<br>6.Җөмләдә нинди мәгънә бәйләнешен белдерә? |
| Тема 7.8.<br>Бәйлекләр  һәм бәйлек сүзләр. | 1.Кадәр, белән, соң сүзләренә сорау куеп буламы?<br>2.Рус телендә бу сүзләр урнына нәрсәләр кулланыла?<br>3.Сүз тәртибендәге аермалары бармы? |
| Тема 7.9.<br>Хәбәрлек һәм модаль сүзләр | 1.Модаль  сүзләр,ягъни эндәш һәм кереш сүзләр  - нинди синтаксик күренеш?<br>2.Составы ягыннан  модаль  сүзләр  нинди була?<br>3.Алар янында нинди тыныш билгеләре куела? |
| Тема 7.10.<br>Кисәкчәләр | 1.Кисәкчәләр ничек языла?<br>2. Калын әйтелешле сүз янында нинди кисәкчә килә?<br>3.Саңгырау тартыкларга беткән сүзләр янында:<br>4.Саңгырау тартыкларга беткән сүзләр янында нинди кисәкчәләр килә? |
| Тема 7.11.<br>Ымлыклар, ияртемнәр | 1.Ымлыклар нәрсәне белдерәләр?<br>2.Ымлыклар янында нинди тыныш билгеләре куела?<br>3. Эмоциональ ымлыкларны атагыз.<br>4.Императив ымлыкларны атагыз. |
| **8 нчебүлек  МАТБУГАТ  БИТЛӘРЕ** | |
| Тема 8.1.<br>Татар матбугаты | 1.Нинди телдә газета-журналлар күбрәк басыла?<br>2.Сез быел газета-журналларга язылдыгызмы? |
| Тема 8.2.<br>Һөнәргә кагылышлы газета-журналлар | 1.Газета-журналларны укырга яратасыңмы?<br>2.Нинди мәкаләләр күбрәк охшый?<br>3.Ни өчен?<br>4.Синең мәкалә язганың бармы? |

| | |
|---|---|
| **9 нчы бүлек СИНТАКСИС** | |
| Тема 9.1.<br>Җөмләдә сүзләр бәйләнеше | 1.Нәрсә ул җөмлә?<br>2.Җөмлә нәрсәләрдән төзелә?<br>3.Нәрсә ул җөмләдә сүзләр бәйләнеше? |
| Тема 9.2.<br>Сүзтезмә. | 1.Сүзтезмә дип нәрсәгә әйтәләр?<br>2.Кайсы сүзнең иртүче булуына карап нинди сүзтезмәләр булалар?<br>3. Сүзтезмә белән тезмә сүз нәрсәсе белән аерылы тора?<br>4. Сүзтезмәләрнең синонимлыгы нәрсә ул? |
| Тема 9.3.<br>Җөмлә | 1. Җөмлә нәрсәләрдән төзелә?<br>2. Җөмлә ахырында нинди тыныш билгеләре куела?<br>3.Ноктакуелганҗөмләне нинди тавыш белән әйтәбез?<br>4. Сорау куелганҗөмләне нинди тавыш белән әйтәбез?<br>5.Өндәү куелганҗөмләне нинди тавыш беләнәйтәбез? |
| Тема 9.4.<br>Җөмләнең баш кисәкләре | 1.Нәрсә ул җөмлә?<br>2.Жөмләләр нәрсә ярдәмендә төзелә?<br>3.Җөмләләр эчендәге сүзләрне нәрсә дип атыйлар?<br>4.Нәрсә ул ия?<br>5.Хәбәр дип нәрсәгә әйтәләр? |
| Тема 9.5.<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре | 1.Җөмләнең иярчен кисәкләренә нәрсәләр кертә?<br>2)Тәмамлык үзе нинди төрләргә бүленә соң?<br>3) Туры тәмамлык дип нәрсә атала соң?<br>4) Кыек тәмамлык дип нәрсә атала?<br>5) Хәлнең нинди төрләре бар? |
| Тема 9.6.<br>Гади җөмлә төрләре | 1.Гади җөмлә дип нинди җөмләне атыйлар?<br>2.Гади җөмлә төрләрен санап чыгыгыз.<br>3.Гади җөмлә составында ничә хәбәрлек булырга мөмкин? |
| Тема 9.7.<br>Кушма җөмлә | 1.Кушма җөмлә дип нинди җөмләне атыйлар?<br>2. Кушма җөмлә төрләрен санап чыгыгыз.<br>3.Кушма җөмлә гади җөмләдән нәрсә белән аерылып тора? |
| **10 нчы бүлек ҺӨНӘРГӘ КАГЫЛЫШЛЫ ТЕКСТЛАР** | |
| Тема 10.1.<br>Һөнәргә кагылышлы текстлар | 1.Нинди текстлар була?<br>2.Нәрсә ул текст?<br>3.Һөнәргә кагылышлы текстлар башклардан нәрсәсе белән аерыла? |
| Тема 10.2.<br>Туры һәм кыек сөйләм | 1. Нәрсә ул туры сөйләм?<br>2. Нәрсә ул кыек сөйләм?<br>3.Чит сөйләм дип нәрсәне атыйлар?<br>4. Нәрсә ул сөйләм?<br>5. Нәрсә ул автор сөйләме? |
| **11нче бүлек ЭРЕТЕП ЯБЫШТЫРУ ҺӨНӘРЕНЕҢ НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ** | |
| Тема 11.1.<br>Эретеп ябыштыру һөнәре, аның тарихы | 1. Һөнәрегезнең тарихын сөйләгез?<br>2. Көллиятебездә эретеп-ябыштыручылар арасында хатын-кызлар бармы? Алар турында сөйләгез.<br>3. 20 нче гасырда эретеп ябыштыру өлкәсендә ничек эшләгәннәр?<br>4. Эретеп ябыштыручылар нинди өлкәләрдә эшлиләр? |
| Тема 11.2.<br>Хәзерге эретеп ябыштыру эшчәнлеге | 1. 21 нче гасырда эретеп ябыштыру өлкәсендә нинди үзгәрешләр бар?<br>2. Хәзерге вакытта эретеп ябыштыру һөнәре өчен кирәкле җиһазлар үзгәргәнме?<br>3. Су астында эретеп ябыштыру мөмкинме? Ничек уйлыйсыз? |

| | |
|---|---|
| | 4. Киләчәктә эретеп ябыштыру өлкәсе үзгәрерме? Нинди яңалыклар булуы мөмкин? |
| **Арадаш аттестация** | Диф.зачет. |

**Телдән бәяләү өчен критерийлар:**

1. Җөмләләр дөрес төзелсә, сорауларга тулысынча җавап бирелсә, һөнәргә кагылышлы сүзләр кулланылса, нәтиҗә тулысынча чыгарылса,– “5” билгесе куела.
2. Җөмләләр дөрес төзелсә, сорауларга тулысынча җавап бирелсә,һөнәргә кагылышлы сүзләр аз кулланылса, нәтиҗә тулысынча чыгарылмаса “4” билгесе куела.
3.Җөмләләр дөрес төзелсә,сорауларның яртысына гына җавап бирелсә, һөнәргә кагылышлы сүзләр аз кулланылса, нәтиҗә тулысынча чыгарылмаса– “3” билгесе куела.
4. Җөмләләр дөрес төзелмәсә; сорауларга тулы җавап булмаса, нәтиҗә чыгарылмаса – “2” билгесе куела.

**2.2. Гамәли эшләр исемлеге** (гамәли эш өчен методик күрсәтмәләр эшкәртмәсе эшләнелгән)

| Теманың номеры | Гамәли эшләр исемлеге |
|---|---|
| Тема 1.2. | 1 нче гамәли эш:<br>Аралашу төрләре |
| Тема 2.1. | 2 нче гамәли эш:<br>Һөнәр сайлау |
| Тема 3.1. | 3нче гамәли эш:<br>Сузык авазлар |
| Тема 3.2. | 4 нче гамәли эш:<br>Тартык авазлар |
| Тема 4.1. | 5 нче гамәли эш:<br>Синонимнар |
| Тема 4.2. | 6 нчы гамәли эш:<br>Антонимнар |
| Тема 4.3. | 7 нче гамәли эш:<br>Омонимнар |
| Тема 4.4. | 8 нче гамәли эш :<br>Фразеология |
| Тема 6.1. | 9 нчы гамәли эш:<br>Белешмә<br>10 нчы гамәли эш:<br>Раслама |
| Тема 6.2. | 11 нче гамәли эш:<br>Әмер |
| Тема 6.3. | 12 нче гамәли эш:<br>Хат.Рәсми хат. |
| Тема 6.4. | 13 нче гамәли эш:<br>Тәрҗемәи хәл |
| Тема 6.5. | 14 нче гамәли эш:<br>Беркәтмә |
| Тема 7.4. | 15 нче гамәли эш:<br>Алмашлыкларның төркемчәләре |
| Тема 7.8. | 16 нчы гамәли эш:<br>Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр |
| Тема 7.9. | 17 нче гамәли эш:<br>Хәбәрлек һәм модаль сүзләр |
| Тема 7.10. | 18 нче гамәли эш:<br>Кисәкчәләр |
| Тема 7.11. | 19 нчы гамәли эш:<br>Ымлыклар ияртемнәр |
| Тема 8.1. | 20 нче гамәли эш:<br>Татар матбугаты |
| Тема 8.2. | 21 нче гамәли эш:<br>Һөнәргә кагылышлы газета-журналлар |
| Тема 9.1. | 22 нче гамәли эш: |

| | |
|---|---|
| | Җөмләдә сүзләр бәйләнеәше |
| Тема 9.2. | 23 нче гамәли эш:<br>Сүзтезмә |
| Тема 9.3. | 24 нче гамәли эш:<br>Җөмлә |
| Тема 9.4. | 25 нче гамәли эш:<br>Җөмләнең баш кисәкләре |
| Тема 9.5. | 26 нчы гамәли эш:<br>Җөмләнең иярчен кисәкләре |
| Тема 9.6. | 27 нче гамәли эш:<br>Гади җөмлә төрләре |
| Тема 9.7. | 28 нче гамәли эш:<br>Кушма җөмлә |
| Тема 10.1. | 29 нчы гамәли эш:<br>Һөнәргә кагылышлы текстлар |
| Тема 10.2. | 30 нчы гамәли эш:<br>Туры һәм кыек сөйләм |

### 2.3. Бүлек һәм темалар буенча тикшерү эшләре

**1 нче тикшерү эше.**
**Кереш диктанты**

**<u>Хезмәт</u>**

Без кулланган һәм алардан башка бер көн дә яши алмаган барлык нәрсәләр дә диярлек – кеше кулының эше, хезмәт нәтиҗәсе. Кеше үзенең хезмәте, куллары, акылы һәм энергиясе тудырган әйберләр белән данлыклы.

Хезмәт кешенең үзен дә барлыкка китергән, шуның нәтиҗәсендә кеше камилләшә бара. Хезмәттә кешенең сәләте һәм таланты ачыла, белеме киңәя. Кеше физик яктан ныгый, аның ихтыяры һәм характеры чыныга. Чөнки хезмәт ул – көч кую да, түземлелек тә, тырышлык та, тегәллек тә, пөхтәлек тә, башкаручанлык та, тапшырылган эшкә җаваплылык та.

Безнең ил – үзеңнең көчеңне һәм сәләтеңне кулланырга мөмкин булган гаять зур эшчәнлек мәйданы ул. Берәүләр төрле-төрле машиналар төзи, икмәк үстерә, файдалы казылмалар чыгара. Икенчеләре китаплар, картиналар, музыка яза, спектакльләр куя, кинофильмнар төшерә. Өченчеләре энергиянең яңа төрләрен эзли, табигать серләрен ача, галәмне өйрәнә.

(120 сүз)

**Диктантларны бәяләү**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм бер пунктуацион хаталы эшкә. | «5» ле билгесе куела. |
| 2. | 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки, орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4» ле билгесе куела. |
| 3. | 4 пунктуацион, 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы | «3» ле билгесе куела. |
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2» ле билгесе куела. |

**2 нче тикшерү эше.**
**“Итәгатьле аралашу” дигән темага хикәя төзеп язу.**

Бәяләү өчен критерийлар:

1. Тема тулысынча ачылса, җөмләләр төзелеше ягыннан дөрес төзелсә, грамматик хаталар булмаса – “5” билгесе куела.
2. Тема тулысынча ачылса, җөмләләр төзелеше ягыннан дөрес төзелсә, 2 грамматик хата булса - “4” билгесе куела.
3. Тема тулысынча ачылса, 5 хата (мәсәлән, бер орфографик, бер грамматик, бер пунктуацион, ике стиль хаталары) булса – “3” билгесе куела.
4. Тема тулысынса ачылмаса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелмәсә; 7 хата китсә – “2” билгесе куела.

**3 нче тикшерү эше.**
**Иҗади эш: “Минем яраткан һөнәрем” дигән темага инша язарга**
***Бәяләү өчен критерийлар:***

1. Тема тулысынча ачылса, җөмләләр төзелеше ягыннан дөрес төзелсә, грамматик хаталар булмаса – “5” билгесе куела.
2. Тема тулысынча ачылса, җөмләләр төзелеше ягыннан дөрес төзелсә, 2 грамматик хата булса - “4” билгесе куела.
3. Тема тулысынча ачылса, 5 хата (мәсәлән, бер орфографик, бер грамматик, бер пунктуацион, ике стиль хаталары) булса – “3” билгесе куела.
4. Тема тулысынса ачылмаса, җөмләләр грамматик яктан дөрес төзелмәсә; 7 хата китсә – “2” билгесе куела.

## 3.Арадаш аттестациянең тикшерү-бәяләү материаллары
## 3.1. Фән буенча йомгаклау аттестациясе, диф.зачет

**Студентлар өчен бирем.**

| МЦК председателе | Директорның ТБ буенча урынбасары |
|---|---|
| тарафыннан каралды | тарафыннан расланды |
| “ _____” __________ 20___ ел. | “____” _______20 __ ел. |

**I вариант**

Хөрмәтле студент!

Эшләргә тотынганчы биремнәрне игътибар белән укыгыз. Бирелгән бирем 3 өлештән (А,В,С) тора:

**А. Тестлар белән эш.**

Барлыгы 30 сорау, һәрбер сорауга 1 бал. Бирелгән битләргә дөрес җавапларны сайлап язарга. Мәсәлән: 1.в.

Барлык сорауларга дөрес җавап бирсәгез “А” өлешендә 30 бал җыярсыз.

**В. Сорауларга җавап.**

Барлыгы 5 сорау, сорауларның һәрберсенә тулы җавап язарга. Һәрбер җавап өчен 4 бал куела. Тулы һәм дөрес итеп язылган җаваплар нәтиҗәсендә 20 бал куела.

**С. Кечкенә күләмдә язма эш**

Эш кәгазьләреннән бер үрнәк язарга. Дөрес, тулы итеп язылган эшкә 10 бал куела.

**Тикшерү-бәяләү материалын эшләү өчен 80 минут бирелә.**

**Максимал бал – 60 бал җыелса “5” билгесе куела**

**Бәяләү критериясе**

**90%тан күберәк бал җыйсагыз “5” билгесе;**
**90% тан алып 70% ка кадәр - “4” билгесе;**
**70% тан алып 50% ка кадәр – “3” билгесе;**
**50% тан ким булса -”2” билгесе.**

***А1. Нокталар урынына кирәкле авазларны язарга:***

***Би...ләй, эл...ктр...д, р...з...на к...л...ме, эр...т...п яб...шт...ру а...пар...ты.***

***А2. Сүзтезмәләрне дөрес итеп язарга.***

а) кура а)алма
б) әче б)җиләге
в)яшел в) торма

***А3. Рабочий сүзенең тәрҗемәсен табарга***

а) кияү

б) эшче
в) камыр
***А4.Аралашу гадәттә нинди формада бара?***
а) монолог
б) диалог
в) трилог
***А5.Кагыйдәләрне язып бетерергә;***
а) эшлекле аралашу -__________________
б) этикет-____________________________
в) диалог - ___________________________
***А6.Эш урынындагы таләпләрне санап чыгарга:_________________***
***А7.Һөнәр –ул .... дигән мәгънәне аңлата***
а) укытучы, галим, акыллы
б) ялкау,ышанычсыз, акылсыз
в) осталык, булганлык, булдыручанлык
***А8. Һөнәргә кагылышлы 5 сүз язарга: ___________________***
***А9. Газета сүзенең дөрес тәрҗемәсен тап***
а) гаҗет
б) гадәти
в) гәҗит
***А10. "Тылсымлы" сүзләрне табарга***
а) "Кирәк", "Бар", " Алып кил!"
б) "Рәхмәт!","Тыныч йокы!", "Гафу итегез!"
в) "Барма!", "Килмә!", "Алып кит!"
***А11. Әлеге җөмләнең иянсен табып, килешен дөрес билгеләгез.*** **Мин урманга барам.**
а) Барам – Ю.к.
б) Урманга - И.к.
в) Мин - Б.к.
***А12.*** **Акыллы** ***сыйфатының синонимын языгыз : _________________***
***А13.Төшеп калган сүзне табыгыз:Бүген көллияткә эретеп ябыштыру өчен ....... алып кайттылар.***
а) күлмәк
б) металлар
в) урындык
***А14. Әлеге җөмләдән рәвешне язып алыгыз.*** **Марат өенә бик тиз кайтты.**

_________________

***А15. Күбесенчә гәҗитләрдә нинди жанр кулланыла***
а) дастан
б) мәкалә
в) баллада
***А16. Ялгызлык исемнәрен тап.***
а) урман, агач

б) китап, дәфтәр
в) Мәскәү, Идел

***А17.Ясалма исем:***
а) килеш кушымчасы ярдәмендә ясала
б) сүз ясагыч кушымча ярдәмендә ясала
в) тартым кушымчасы ярдәмендә ясала
***А18.Конкрет эшкә кагылышлы телдән оештырылган әңгәмә – ул....***
а) эшлекле аралашу
б) этикет
в) эшлекле сөйләшү
***А19.Алмашлыклар төркемчәләрен санап чыгыгыз:_________________***
***А20. Авторның уй-фикерләрен, хис-тойгыларын бөтен барлыгы белән аңлатырга ярдәм итә торган, телнең бөтен байлыгын чагылдыра торган стиль***
а) Матур әдәбият стиле;
б) Фәнни стиль.
в) Рәсми стиль;
***А21.Синонимнарны билгелә:***
а) шатлыклар,сөенечләр
б) шатлыклар,кайгылар
в) уйный, карый
***А22. Кушма саннарны яз.***
***А23.Җете кызыл – сыйфаты ниди дәрәҗәдә?***
а)кимлек
б) чагыштыру
в) артыклык
***А24.Фигыль нинди сорауларга җавап бирә?***
а) кем?
б) нинди?
в) нишли?
***А25.Дөрес сүзтезмәне табарга:***
а) кояшлы көн
б) алма кызыл
в)көн кояш
***А26. Сыйфатның ничә дәрәҗәсе бар?***
а) 4;
б) 3;
в) 5.
***А27.Рәвеш - нинди сүз төркеме?***
а) эш яки хәлнең билгесен белдерүче
б) төрләнми торган сүз төркеме
в) җөмләдә эш яки хәлнең билгесен белдереп, ничек? , кая? , кайдан? , кайчан? , һ.б. сорауларга җавап бирүче, төрләнми торган сүз.
***А28.Җөмләнең билгеләмәсен яз -___________________________***
***А29.Кушма җөмлә ул -...***

А) бер яки ике грамматик нигезе  булган җөмлә
Б)ике яки икедән артык грамматик нигезе  булган җөмлә
В) бер генә грамматик нигезе  булган җөмлә
***А30. Әлеге җөмләнең русча тәрҗемәсен языгыз.***
**Авыл малайлары урманда чикләвек җыялар иде.**
**______________________________________________**

**В1. Гади һәм кушма җөмләләрнең төрләрен мисаллар белән күрсәтергә?**
**В2.Нәрсә ул – белешмә?**
**В3.Туры сөйләм дип нәрсәне атыйлар?**
**В4. Нәрсә ул – раслама (расписка)?**
**В5. “Шифалы”  сүзләрне язарга.**

**С1. Һөнәргә кагылышлы  текст төзергә**

МЦК председателе
тарафыннан каралды
___________
“_____” __________ 20___ел.

Директорның ТБ буенча урынбасары
тарафыннан расланды
___________
“____” _______20___ ел.

**II вариант**

Хөрмәтле студент!
Эшләргә тотынганчы игътибар белән укыгыз. Бирелгән бирем 3 өлештән  (А,В,С) тора:
**<u>А. Тестлар белән эш.</u>**
Барлыгы 30 сорау, һәрбер сорауга 1 бал. Бирелгән битләргә дөрес җавапларны сайлап язарга. Мәсәлән: 1.в.
Барлык сорауларга дөрес җавап бирсәгез “А” өлешендә  30 бал җыярсыз.
**<u>В. Сорауларга җавап.</u>**
Барлыгы 5 сорау, сорауларның һәрберсенә тулы җавап язарга. Һәрбер җавап өчен 4 бал куела. Тулы һәм дөрес итеп язылган җаваплар нәтиҗәсендә  20 бал куела.
**<u>С. Кечкенә күләмдә язма эш</u>**
Эш кәгазьләреннән бер үрнәк язарга. Дөрес, тулы итеп язылган эшкә 10 бал куела.
**<u>Тикшерү-бәяләү материалын  эшләү өчен 80 минут бирелә.</u>**

**Максимал бал – 60 бал җыелса  “5” билгесе куела**

**<u>Бәяләү критериясе</u>**
**90%тан  күберәк  бал җыйсагыз  “5” билгесе;**
**90% тан алып 70% ка кадәр  - “4” билгесе;**
**70% тан алып 50% ка кадәр – “3” билгесе;**
**50% тан ким булса -”2” билгесе.**

***А1. Аралашу гадәттә нинди формада бара?***

а) монолог

б) диалог

в) трилог

***А2.Кагыйдәләрне язып бетерергә;***

а) эшлекле аралашу -__________________

б) этикет-______________________________

в) диалог - ____________________________

***А3. Гафу итү сүзенең синонимы:***

а) кичерегез

б) җибәрегез

в) китегез

***А4. Эретеп ябыштыручы һөнәренә кагылышлы өч сүзне атарга:***

***__________________***

***А5.Һөнәр –ул .... дигән мәгънәне аңлата***

а) укучы, галим, акыллы

б) ялкау,ышанычсыз, акылсыз

в) осталык, булганлык, булдыручанлык

***А6. Зат алмашлыкларын атагыз: _________________***

***А7.Конкрет эшкә кагылышлы телдән оештырылган әңгәмә – ул....***

а) эшлекле аралашу

б) этикет

в) эшлекле сөйләшү

***А8. Эш урынындагы таләпләр:***

а) уңай, чиста, төзек

б) уңай, пычрак, эшләми

в) пычрак,төзек

***А9. “Шифалы” сүзләрне табарга***

а) Исәнмесез! Хәлләрегез ничек? Кәефләрегез ничек?

б) Начар кеше. Бәхетсезлек. Кирелек

в) Кайгы-хәсрәт. Эчкерлек. Мактанчык

***А10. Барырга фигыленең хәзерге, үткән һәм киләчәк формасын язгыгыз____________________***

***А11.Икмәк сүзенең тәрҗемәсен табыгыз***

а) масло

б) молоко

в) хлеб

***А12. Сүзтезмәләрне дөрес итеп төзегез***

| | |
|---|---|
| а) каз | а) кикриге |
| б) әтәч | б) мөгезе |
| в) үгез | в)канаты |

***А13. Төшеп калган сүзне табыгыз: Эретеп ябыштыручы тимер өстәлне ....... белән ябыштырды.***

а) аргон

б) ботканы

в) чүлмәкне

***А14. “Эретеп ябыштыру өлкәсе”, “Эретеп ябыштыручы серләре”, “Россия эретеп ябыштыручылары” журналлары нинди һөнәргә карый***

а) эретеп ябыштыручы

б) итекче

в) монтажчы

***А15. Рабочий сүзенең тәрҗемәсен табарга.***

а) кияү

б) эшче

в) камыр

**А16.Аралашу гадәттә нинди формада бара?**

а) монолог

б) диалог

в) трилог

***А 17. Иярченле кушма җөмләдә ...***

а) бер җөмлә икенчесенә ияреп, буйсынып килә

б) мөстәкыйль мәгънәле ике яки икедән артык сүз үзара ачыклаулы мөнәсәбәттә тора

в) ике яки икедән артык иярчен җөмлә бер баш җөмләгә ияреп килә

***А18.“Эше барның ашы бар” - җөмләсендә нинди тыныш билгесе куела?***

а) өтер куела

б) тыныш билгесе куелмый

в)Ике нокта

***А19. Фигыль төркемчәләрен санап чыгыгыз:____________________***

***А20.Фигыль нинди сорауларга җавап бирә?***

а) кем?

б) нинди?

в) нишли?

***А21.Дөрес сүзтезмәне табарга:***

а) кояшлы көн

б) алма кызыл

в)көн кояш

***А22. Антонимнарны билгелә:***

а) шатлыклар,сөенечләр

б) көенеч, сөенеч

в) уйный, карый

***А23. Дистәләрне яз.***

***А24.Татар телендә ничә килеш бар?***

а)5

б) 6

в) 4

***А25.“Авылымның” - сүзе нәрсәләр белән төрләнгән?***

а) Килеш белән

б) килеш һәм тартым белән
в) тартымлы исем килеш белән
***А26. Сыйфатның билгеләмәсен язарга:***____________
***А27. Мәгънәләре ягыннан рәвешләр ничә төркемгә бүленә?***
а) 4;
б) 5;
в) 6
***А28. Кайсысы чама сан?***
а) өчәр
б) унлап
в)унбишәү
***А29.Хикәя фигыльнең ничә заманы бар?***
а) өч
б) ун
в) дүрт
***А30. "Барлык, андый,тегеләй, ниндидер, бу" бу алмашлыклар төзелешләре ягыннан ниндиләргә керәләр?***
а/ тамыр
б/ ясалма
в/ кушма

**В1.Рәсми хат башка хатлардан нәрсәсе белән аерыла?**
**В2.Исем ясаучы кушымчаларны санап чыгарга?**
**В3. Гариза дип нәрсәгә әйтәләр?**
**В4. Зат алмашлыкларын санап чыгарга?**
**В5. Беркетмә дип нәрсәне атыйлар?**

**С1.Тәрҗемәи хәлем язарга**

## 3.2. Җаваплар эталоны

**<u>I Дифференциаль зачетны үткәрү шартлары</u>**

Дифференциаль зачет вакытында төркем бүленми.
Һәр студентка 2 вариантның берсе бирелә.
Һәрбер бирем программа буенча үтелгән темаларның ничек үзләштерүен тикшерә.
Җаваплар язма рәвешендә кабул ителә.
**Биремнең үтәлү вакыты:** Тәнәфессез, 2 сәгать бирелә.
**Җиһазлау:** кәгазьләр, каләм, биремнәр, сүзлекләр.

**<u>II Җаваплар эталоны</u>**

Тикшерү эшләрендә барлык биремнәргә дөрес җаваплар бирелгән:

**<u>"А" өлеше:</u>**

| № | Вариантлар | |
|---|---|---|
| | **I** | **II** |
| 1 | Бияләй, электрод, резина keләме, эретеп ябыштыру аппараты. | б |
| 2 | а-б<br>б-в<br>в-а | 1.Нинди дә булса мөһим мәсьәләне хәл итү, бер карага килү, килешү.<br>2. Үз-үзеңне тиешле рәвештә тоту кагыйдәләре җыелмасы.<br>3.Репликалардан торган сөйләм |
| 3 | б | б |
| 4 | б | Бияләй, электрод, резина келәме, эретеп ябыштыру аппараты. |
| 5 | 1.Нинди дә булса мөһим мәсьәләне хәл итү, бер карага килү, килешү.<br>2. Үз-үзеңне тиешле рәвештә тоту кагыйдәләре җыелмасы.<br>3.Репликалардан торган сөйләм | а |
| 6 | Чиста, пөхтә, уңайлы | Мин, без; син, сез; ул, алар. |
| 7 | в | а |
| 8 | Бияләй, электрод, резина келәме, эретеп ябыштыру аппараты. | а |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | в | а |
| 10 | б | Бара, барды, барачак |
| 11 | б | в |
| 12 | Зирәк, белемле. | а-в<br>б-а<br>в-б |
| 13 | б | а |
| 14 | Тиз | в |
| 15 | б | б |
| 16 | в | б |
| 17 | б | а |
| 18 | а | б |
| 19 | Зат, күрсәтү, тартым, сорау, билгеләү, билгесезлек, юклык | в |
| 20 | а | в |
| 21 | а | б |
| 22 | Унбер, унике, унөч, ундүрт, унбиш, уналты, унҗиде, унсигез, унтугыз | б |
| 23 | в | Ун, егерме, утыз, кырык, илле, алтмыш, җитмеш, сиксән,туксан |
| 24 | в | б |
| 25 | б | б |
| 26 | а | Предметның билгесен белдереп, *нинди? кайсы? кайдагы?* кебек сорауларга җавап булган <u>сүз төркеме</u> |
| 27 | в | в |
| 28 | Сүзләрнең грамматик яктан оештырылган кушылмасыннан гыйбарәт булган телнең минималь берәмлеге. | б |
| 29 | б | а |
| 30 | Сельские мальчишки собирали орехи в лесу. | б |

**“В” өлеше:**

| № | Вариантлар | |
|---|---|---|
| | I | II |
| 1 | Бер генә хәбәрлектән торган җөмләләр **гади** җөмләләр дип атала. Кимендә ике хәбәрлекнең үзара структур-семантик, интонацион һәм грамматик яктан бер бөтенлек тәшкил иткән синтаксик берәмлек кушма җөмлә дип атала.<br>Кушма җөмләләр, ике, өч, һәм, хәтта күбрәк — ун җөмләдән торып, структур-семантик һәм интонацион яктан синтаксик бөтен тәшкил итәләр.<br>**Кушма** җөмләләрне билгеләгәндә, түбәндәге структур калыпларны истә тоту зарур. | Рәсми хат башка хатлардан аерылып тора:<br>-эш урынында языла;<br>- һөнәргә карата аерым терминнар |
| 2 | <u>Белешмә</u> - теге яки бу фактны һәм вакыйганы раслап, кирәкле мәгълүмат бирүче рәсми документ. | Исем ясаучы кушымчалар: -ма, -мә, -даш, -дәш, -таш, -тәш,-чы, -че, -лык, -лек, -гыч, -геч, -кыч, -кеч, -ым, -ем һ.б. (колхозчы, дуслык, чордаш, иптәш) |
| 3 | Үзгәртелмичә кулланылган чит сөйләм **туры сөйләм** дип атала.*(“Дүшәмбе көн класс җыелышы булачак “,- дип хәбәр итте укытучы.)* Үзгәртелеп кулланылган чит сөйләм кыек сөйләм дип атала. *(Дүшәмбе көн класс җыелышын буласын хәбәр итте укытучы).* | Гариза ул - язма рәвештә рәсми формада язылган шәхси үтенеч (эшкә, уку йортына һ.б. кабул итү, нәрсәгәдер рөхсәт сорау һ.б.). Гариза кулдан языла. |
| 4 | <u>Раслама (расписка)</u> – берәр нәрсә алганлыкны раслап имза куелган рәсми язу, документ. Раслама, гадәттә, акча, кыйммәтле әйберләр, документлар алганда языла. | Зат алмашлыклары: мин, син, ул, без, сез, алар. Алар сөйләү процессына катнашка затларны белдерәләр. |
| 5 | Рәхим итегез, хәерле иртә, гафу итегез, хәерле көн, рөхсәт итегез, хәерле кич, исәнмесез, мөмкинме? Сау булыгыз, рәхмәт, хушыгыз, зинһар, юлларыгыз уң булсын, армый эшләгез. | Беркетмә - җыелыш, киңәшмә, конференция һ.б.ш. чараларның барышын төгәл итеп язып бара торган документ. |

**“С” өлеше:**

| | |
|---|---|
| **I** | **Һөнәргә кагылышлы текст төзергә**<br><br>Минем булачак һөнәрем.<br><br>Һәрберебез бала чактан ук булачак һөнәре турында хыяллана, тормышта үз урыны хакында уйлана. Мин үзенең профессиясенең кадерен белүче, яраткан эшенә бөтен гомерен багышлаучы кешеләргә баш иям.<br>Минем эретеп ябыштыручы һөнәре буенча эшлисем килә. Кечкенә вакыттан ук мине төрле металлар һәм аларны ябыштыру кызыксындыра иде. Әтием дә эретеп ябыштыручы булып эшли. Мәктәпне тәмамлагач тормышымны элеге һөнәр белән бәйләргә булдым. Әлбәттә иң беренче чиратта без уку йортын сайларга тиеш, шуның өчен мин шәһәребезнең барлык уку йортлары турында мәгълүмат җыйдым, нинди һөнәрләр баргылыгын белештем. Хәзер инде мин НМК көллиятендә, беренче курста яраткан һөнәрем бүлегендә укыйм.<br>Эретеп ябыштыручы – хөрмәтле кеше, егерме беренче гасырда да без моны аңлыйбыз, шуның өчен мин эретеп ябыштыручы булырга телим. Менә ул нинди кирәкле, шәфкатьле һәм заманча һөнәр! |
| **II** | **<u>Тәрҗемәи хәлем</u>**<br><br>**(автобиография)**<br><br>Мин, Хафизов Айрат Рәшит улы, 1997 нче елның 4 нче маенда Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәрендә туганмын.<br>2000 нче елда мин 2 нче татар гимназиясенең беренче сыйныфына укырга кердем. 9 нчы сыйныфны тәмамлагач НМК га эретеп ябыштыручы һөнәренә укырга кердем. Мин әдәбият, тарих, математика фәннәрен яратам. Хәзерге вакытта 2 нче курсста укыйм.<br>Мин – гаиләбездәге ике баланың беренчесе. Әтием Хаҗи заводта, ә әнием татар гимназиясендә укытучы булып эшли. Сеңлем 2 гимназиянең 3 нче сыйныфында укый.<br>Киләчәктә югары уку йортына укырга керергә телим.<br><br>20 нче май, 2023 нче ел. Имзам: ______________ |

## 3.3. Зачет ведомосте

Дифференциальләштерелгән зачет зачет ведомосте белән рәсмиләштерелә, ул укыту бүлегенә яисә җаваплы директор урынбасарына тапшырыла. Дифференциаль зачет нәтиҗәләре журналга күчерелә һәм студентның йомгаклау билгесен чыгарганда исәпкә алына.